КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 июнь г.Казань № 498

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының аерым нормалары гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының аерым нормалары гамәлдә булуын туктатып торырга.
2. Бу карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 16 июнь, 498 нче
карарына кушымта

2021 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә булулары туктатылып торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасында коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Ккабинетының «Татарстан Республикасында студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтен үстерүгә һәм яклауга юнәлдерелгән социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмаларга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 20 май, 330 нчы карары.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 6 август, 539 нчы карары.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм Бөтенроссия спорт ярышларында югары казанышлар өчен спортчыларга һәм тренерларга дәүләт ярдәме турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карарының 1 пунктындагы дүртенче абзацы.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 26 ноябрь, 1082 нче карары.